# Д.Б. РАМАЗАНОВАНЫҢ «ФОРМИРОВАНИЕ ТАТАРСКИХ ГОВОРОВ ЮГО-ЗАПАДНОГО БАШКОРТОСТАНА» КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

Яңа гына күренекле тел галиме, диалектолог, бу өлкәдә күпсанлы хезмәтләре белән танылган Дөрия Бәйрәм кызы Рамазанованың «Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии» хезмәтенең икенче басмасы нәшер ителде (Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западного Башкортостана. 2-е изд. Казань: ИЯЛИ, 2021. 208 с.).

Д.Б. Рамазанова 1968 елдан Башкортстанның көньяк-көнбатышындагы татар сөйләшләре таралган төбәкне өйрәнә башлый. Галимә Башкортстанның Авыргазы, Әлшәй, Бәләбәй, Бишбүләк, Благовар, Бүздәк, Дәүләкән, Ярмәкәй, Кырмыскалы, Күмертау, Мәләвез, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Туймазы, Федоровка, Чишмә районнарына һәм Татарстанның Баулы районына караган 116 торак пунктка экспедицияләргә чыгып, бай тел, этнографик, фольклор материалларын туплый, аларны фәнни аңлату өстендә эшли. Аның фәнни күзәтүләре, тикшеренү нәтиҗәләре төрле фәнни җыентыкларда басылган күпсанлы мәкаләләрдә урын ала, ә 1984 елда «Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии» дигән исем белән китабы дөнья күрә. Хезмәттә тел, тарих, архив материаллары нигезендә Башкортстан Республикасының көньяк-көнбатышында таралган татар сөйләшләренең формалашу тарихы карала.

Монография ике бүлектән һәм кушымталардан тора. Китап икенче басмага кереш сүз, автор сүзе, керештән, «Хәзерге Көнбатыш Башкортстан татарларының формалашу тарихының кайбер мәсьәләләре (Некоторые вопросы истории формирования татар современной западной Башкирии)» дигән беренче, урта диалектның минзәлә сөйләше бәләбәй урынчылыгының һәм көнбатыш диалект стәрлетамак сөйләшенең фонетик, грамматик үзенчәлекләрен тасвирлаган «Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарында таралган татар сөйләшләре (Татарские говоры, распространенные в юго-западных районах Башкирии)» дигән икенче бүлектән (89–174 битләр), йомгактан, тулы библиографиядән, автор өйрәнгән торак пунктлар исемлеген, текст үрнәкләрен, Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарындагы татар сөйләшләренең таралу карта-схемасын үз эченә алган кушымталардан тора.

Д.Б. Рамазанова кереш өлешендә мәсьәләнең өйрәнелү торышына туктала. Башкортстан Республикасы территориясендә яшәүче татарларның тарихы, этнографиясе, мәдәнияте, теле һәрвакыт галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итте. Бу төбәктә яшәүчеләрнең тел үзенчәлекләре А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов хезмәтләрендә чагылыш таба. Ә.Ә. Юлдашев, Л.Т. Мәхмүтова, Ж. Алмаз, Ә.Ш. Әфләтунов һ.б. авторларның хезмәтләрендә төрле дәрәҗәдә яктыртылган. XIX гасырның икенче яртысында А.Г. Бессонов Урал тирәсе татарлары

сөйләшләренә күзәтү ясый. Ул аларны татар теленә якынлыклары ягыннан чагыштыра һәм типтәр (билгеле булганча, минзәлә сөйләше вәкилләренең зур өлеше типтәрләр дип йөртелгән) сөйләшләрен казан татарлары теленә иң якын тора торган сөйләш дип билгели [Бессонов, 1881: 231]. Әлеге төбәк вәкилләре турындагы мәсьәләләрне өйрәнгәндә, алдагы чорларда галимнәр белдергән карашларның соңгы тикшеренүләр белән дә раслануы зур әһәмияткә ия. Бу төбәк халкының тел үзенчәлекләрен лингвистик география ысулы белән өйрәнү А.Г. Бессонов һәм югарыда телгә алынган галимнәрнең хезмәтләрендә теркәп калдырылган нәтиҗәләрнең дөреслеген тулысынча исбатлады. Монографиядә бу галимнәрнең, шулай ук башкорт телчеләренең фикерләре тулы чагылыш таба. Д.Б. Рамазанова әлеге галимнәрнең нәтиҗәләрен китерә, аларга карата үз фикерләрен белдерә, проблемага карата авторның үз карашлары урын ала. Ул Башкорстанның көньяк-көнбатышындагы татар сөйләшләре күпмедер дәрәҗәдә мишәр сөйләшләре йогынтысында формалашкан дип дәлилли.

Хезмәтнең беренче бүлеге тулысы белән тарихи чыганакларга, архив материалларына нигезләнгән. Анда Көнбатыш Башкортстан татарларының формалашу тарихына бәйле мәсьәләләр аерым чорларга нисбәттә (Болгар чоры, Казан ханлыгы дәвере һәм Башкортстанны Россия дәүләтенә кушу һ.б.) системалаштырылып яктыртылган, бигрәк тә 1552 еллардан соң булган тарихка ныклы тикшеренүләр ясалган. Галимәнең бу юнәлештәге нәтиҗәләре архив чыганакларына нигезләнеп тә аңлатыла ала. Хезмәтнең эчтәлеге моны ачык раслый. Д.Б. Рамазанова шушы мәсьәләләргә караган бик күп архив документларын фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә.

Д.Б. Рамазанова татарларның Көнбатыш Башкортстанга күчү тарихының башлангычын, Р.Г. Кузеев хезмәтләренә таянып, болгар чоры дип билгели. Фәнни әдәбиятта хәзерге Көнбатыш Башкортстан территориясе халкына, икътисади, мәдәни, иҗтимагый яктан алга киткән дәүләт буларак, Болгарның этник һәм мәдәни йогынтысы турында күп языла. Хәзерге Көнбатыш Башкортстан территориясендә борынгы заманнардан ук тел, тормыш-көнкүреш, икътисади төзелеш һәм культура ягыннан Идел буе татарларына якын төрки халык яшәгән. Автор аларга соңгырак чорда, төрле объектив һәм субъектив сәбәпләр нәтиҗәсендә, күченеп килүчеләрнең тагын берничә дулкын булып өстәлүен билгели. Башта Алтын Урда, аннары патша хакимияте золымыннан канәгать булмаганнарның барысы да зур агым белән Россиянең көнчыгышына һәм көньяк-көнчыгышына – Оренбург далаларына һәм Себергә күчә. Аерым алганда, хәзерге Башкортстан Республикасының көнбатышында күчкән татарлар XVI гасырның икенче яртысыннан бирле яшиләр. Россиягә яңа көньяк-көнчыгыш чикләрен шәһәрләр төзеп (1578 елда Уфа, Бөре, Минзәлә шәһәрләре төзелә башлый) ныгытырга кирәк булганга, татарларны күчереп утырту башлана. 1736 елның 11 гыйнварындагы указ игълан ителгәннән соң, татарлар бу территориягә хөкүмәт рөхсәте белән

урнаштырыла. Шул ук указда фетнәче башкортларның җирләрен кайбер сословие вәкилләренә, аерым алганда, дворяннарга, офицерларга һәм мещерякларга, типтәрләргә сатарга рөхсәт ителә. Галимнәр фикеренчә, XIX гасырда, аеруча аның икенче яртысында, хәзерге Башкортстанның төньяк-көнбатыш төбәкләренә караганда көньяк-көнбатыш өлешенә күченү киң таралган. Д.Б. Рамазанова, «халыкның теле – аның тарихының көзгесе» гыйбарәсен истә тотып, сөйләшләрне шул сөйләш вәкилләренең тарихы белән бәйләп тикшерә. Авторга тарихи фактларга, беренчел чыганакларга таянып өйрәнү сөйләшләрне тасвирлау барышында туган сорауларны ачыкларга, тел күренешләрен объектив һәм дөрес аңлатырга ярдәм итә. Архив документларына нигезләнү Көньяк-Көнбатыш Башкортстандагы татар сөйләшләрен өйрәнүдә үзенә бер төрле мөһим роль уйный. Д.Б. Рамазанова бу сөйләшләр вәкилләренең документларда типтәрләр, башкортлар, ясаклылар, мещеряклар һ. б. дип төрлечә аталып йөртелүләрен исәпкә алып, Уфа, Оренбург, Мәскәү архивларында утыра, күпсанлы чыганакларны барлый, XVI–XIX гасырларга караган тарихи материалларны өйрәнеп, әлеге атамаларның билгеле бер тарихи чорда – XVI–XIX йөзләрдә социаль термин булып та йөргәнлеген фәнни нигездә дәлилләүгә ирешә.

Сөйләш үзенчәлекләрен аңлатканда, Д.Б. Рамазанова, тарихи чыганакларны гына түгел, сөйләш вәкилләренең үзаңы, халык иҗаты әсәрләре, риваятьләр һ.б. – барысын да исәпкә алып эш итә. Шулай итеп, төрле характердагы фактларны комплекслы файдаланып, автор әлеге төбәктә моңарчы аз билгеле булган сөйләшләрне ачыклый. Аның татар сөйләшләренең (бу очракта минзәлә һәм стәрлетамак сөйләшләре) һәм әлеге сөйләшләр вәкилләренең формалашу тарихы буенча гомумиләштерүләре, этнолингвистик үзенчәлекләр буенча материаллар һәм анализ нәтиҗәләре татар халкының этногенезын гына түгел, бәлки татар халкының бу территориядәге тугандаш һәм тугандаш булмаган башка халыклар белән күпгасырлык бәйләнешләрен өйрәнү өчен ышанычлы нигез булып тора. Хезмәттә бу төбәктә татар авылларында яшәүчеләрнең теле, сөйләмнәрендәге фонетик, лексик һәм граматик үзенчәлекләре буенча, татар әдәби теленә якынлыгы билгеләнә. Бер үк вакытта, бу җирлектә башкорт сөйләшләре һәм берникадәр фин-угор этник йогынтысында формалашкан үзенчәлекле ике мөстәкыйль татар сөйләше бүлеп чыгарыла. Бәләбәй урынчылыгының төп диалекталь үзенчәлекләрен карау авторга түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә: авазлар системасы, авазларның артикуляцион һәм позицион үзенчәлекләре, грамматик категорияләрнең төп күрсәткечләре, сүз ясалышы системасы татар әдәби телендәге кебек; төбәк вәкилләре сөйләменең татар әдәби теленә якынлыгы күзгә ташлана. Тирән тел арты *ķ, ғ, х* тартыклары, *җ*-ләштерү, интердентал *d, -ай/-әй* дифтонгы, аваз тәңгәллекләре, хәзерге, киләчәк, нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльнең II зат күплек сандагы *-сығыз* кушымчасы, теркәгечнең киңрәк функциядә кул-

ланылышы һ.б. диалекталь үзенчәлекләр бу урынчылыкны, беренче чиратта, урта диалект сөйләшләренә якынайта.

Татар теленең көнбатыш диалекты вәкилләренең Урал тирәсенә күчүе өч йөз ел буена дәвам иткән. Яңа җирләрдә алар җирле халык, урта диалект вәкилләре белән тыгыз мәдәни-икътисади һәм тел мөнәсәбәтләренә кергәннәр. Бу үзара тәэсир итешү процессында урта диалект төп һәм хәлиткеч рольне уйнаган. Стәрлетамак сөйләше көнбатыш диалектка хас күренешләрнең төрле дәрәҗәдә сакланып килүе (ачык [а] авазы, тел арты *к, г, х* тартыклары, *өй* дифтонгының монофтонглашуы һ.б.), минзәлә сөйләше белән уртак үзенчәлекләр табылу (интерденталь *d, -ай/-әй* дифтонгы, *и ~ у, ә ~ и* тәңгәллекләре, фигыльнең кабатлаулы формасы *-ыңкыра* һ.б.) һәм татар әдәби теленә якын булу белән характерлана. Автор күрсәтүенчә, «урта диалектка һәм мишәр диалектына хас үзенчәлекләрнең активлык дәрәҗәсе төрле җирдә төрлечә һәм ул урыннарда әлеге ике диалект вәкилләренең сан исәбе, аларның бирегә күчеп килү вакыты белән турыдан-туры бәйләнгән» [Рамазанова, 2020, с. 121]. Стәрлетамак сөйләше көнбатыш диалектка хас күренешләрнең төрле дәрәҗәдә сакланып килүе, минзәлә сөйләше белән уртак үзенчәлекләр табылу һәм татар әдәби теленә якын булу белән характерлана.

Тәкъдим ителгән китап – Башкортстан татарларының этник формалашу тарихы һәм аларның туган теле турында ышанычлы, кыйммәтле һәм фәнни яктан нигезле мәгълүмат бирә торган хезмәт. Тикшеренү нәтиҗәләре татар халкы тарихы, татар лингвистикасы һәм төрки тел белеме тарихы проблемаларын өйрәнүдә нигез булып тора ала.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*